# КҮКНЕҢ ҖИДЕНЧЕ КАТЫНДА

Хөрмәтле газета сөючеләребез! Газетабызның бу санында хөрмәтле укытучыларыбызны һөнәри бәйрәмнәре белән котлыйсыбыз килә.
Укытучы – ул изге һөнәр. Балаларыбызның киләчәге – укытучы кулында, аның алтын йөрәгендә. Шуңа күрә кеше тормышында укытучының роле һәм урыны бәяләп бетергесез. Укытучы исеменә лаек булу ул – зур бер батырлык дип әйтер идем мин.

Талантлы укытучы үз белемен башкаларга бирә, авырлыкларны җиңеләйтә, бала күңелен аңлый белә. Моның өчен укытучы булып туарга, гомереңбуе укытучы булып яшәргә кирәк. Укытучы ул һөнәр генә түгел, ул – аның язмышы! Алар балаларны белем дөньясына алып керәләр, яхшыны яманнан аерырга, хезмәт шатлыгын тоярга өйрәтәләр.

Әйе, ничек кенә булмасын, һәр кешенең “менә ул чын укытучы” диярлек остазы бар. Ул аны еллар үткән саен сагынып искә ала, гомер буе аңа рәхмәт укый. “Мин сезнең алдыгызда түбәнчелек белән баш ияр идем” дигән рус шагыйре Н.А.Некрасов.

Укытучы – ул мәктәптә генә түгел, ул урамда булса да, кибеткә керсә дә, укытучы булып кала. Каникул вакытларында һәм, гомумән, һәрвакыт урамда балаларны күреп, алар белән сөйләшми йөрәге түзми. Балаларны мәктәп стеналарында гына түгел, алардан тыш та балага тәрбия, әдәп, әхлак кануннарын аңлатучы ул – чын укытучы.

Укытучы булу җиңел түгел! Укытучы һөнәре – чын мәгънәсендә һөнәрләр һөнәре. Мөгаллим ул – гомере буе укый, өйрәнә, үзенең һәм укучыларының уңышларына чын күңелдән сөенә белүче, көчле ихтыярлы, сабыр кеше. Балаларны яратучы, хөрмәт итүче, барачак юлларында маяк булып торучы изге зат. Башкача мөмкин дә түгел, минемчә, чөнки ул ШӘХЕС тәрбияли. Укытучының үз “чәчү вакыты”, үз “урак өсте” бар. Аларның сабырлыгы аналар сабырлыгына тиң, юкка гына укытучыларны әниләргә тиңләмиләрдер.

Бала күңеленә изгелек орлыклары чәчкәндә, бөтен тормыш тәҗрибәңне, белемеңне балаларга бирергә, күңел җылыңны өләшә белергә кирәк. Шул чакта чәчкән игелек, шәфкатьлелек орлыклары да тигез шытымнар бирә, үсә, тик алар корымасыннар гына иде! Аларны саклап калу – укытучыларның изге бурычы!

Ни өчен дигәндә: бары тик көчле рухлы, сабыр кеше генә бу эшкә күңелен биреп, тиешле дәрәҗәдә укыту сәләтенә ия була аладыр.




**Укытучыма**

Матур, пөхтә, акыллы син –УКЫТУЧЫ,
Газиз, якын, сердәшче син -УКЫТУЧЫ.
Белем дөньясында йөздерүче,аң –белемне бездә тудыручы,
Ул - Сез, минем газиз УКЫТУЧЫ!

Укырга , язарга ,санарга һәм сөйләргә өйрәтүче,
Ул Сез- минем газиз УКЫТУЧЫМ!
Мең рәхмәтләр әйтеп, баш иямен,
Сезнең алда газиз УКЫТУЧЫМ!

**Котлау сүзләре**

Хөрмәтле укытучылар!
Бәйрәм белән котлыйбыз.
Сезгә бәхет, сәламәтлек,
Озын гомер телибез.

Сезгә вәгъдә бирәбез
Гел тырышып укырга.
Тәртипле, тыныч, уңган
Һәм ярдәмчел булырга.

КҮКНЕҢ ҖИДЕНЧЕ КАТЫНДА

## МӘКТӘП ЯҢАЛЫКЛАРЫ



“Яшь буынга кыйммәтле тормыш ориентирлары формалаштыруда мәктәпнең роле”дигән темага узган педсоветта ВПР нәтиҗәләре, алдынгы укучылар белән эш планы, НПК га әзерлек барышы, һб. турында чыгышлар тыңланылды.



26-27 октябрьдә мәктәптә 2022/2023 уку елының 1 чиреге нәтиҗәләре буенча йомгаклау линейкалары узды. Йомгаклар ясалды, лидер-класслар ачыкланды, укуда һәм дәрестән тыш эшчәнлектә иң әйбәтләр бүләкләр алдылар. Сезгә яхшы каникуллар телибез!





Мәктәп укучылары беренче чирекне тәгәлләп килә. Чыгарылыш класс укучыларының иң җаваплы чорлары - бердәм дәүләт имтиханнарына әзерләнәләр. Беренче сынау декабрьдә булачак. Бу көнне 11 класста белем алучы укучылар рус әдәбиятыннан инша язып, бердәм дәүләт имтиханнарына керергә рөхсәткә дәгъва кыла.




21 нче октябрь көнне 10 нчы А сыйныф укучылары “Белем. Карьера» уку урыннары ярминкәсендә булдылар. Анда төрле уку йортлары, һөнәрләр турында мәгълүмат алдылар. Кызыксындырган сорауларына җаваплар ишеттеләр.

21 нче октябрь көнне “Красна девица" исемендәге район бәйгесенең 2 нче этабы узды.

Бу бәйге 3 этаптан тора. Мәктәп туры, район туры һәм шәһәр туры.

Мәктәбебез укучысы Петрочинина Диана рус әдәбияты, тарихы турында белемнәрен күрсәтеп, 1 нче урын яулады. Без аны чын күңелдән уңышлары белән котлыйбыз!

# КҮКНЕҢ ҖИДЕНЧЕ КАТЫНДА

22-23 сентябрь - көзге көн белән төн тигезләшкән вакыт. Елның сихри фасылында, нәкъ менә көн белән төн тигезләшкән мәлдә, татар халкы Сөмбелә бәйрәмен үткәргән. Европалылар өчен бераз моңсу вакыт, чөнки көз-патшабикә хакимлек итәргә тулы хокук ала. Ел фасылы алышынганда көн кыскара, төн озая. Көн озынлыгы нәкъ ярты тәүлек - 12 сәгать булганлыктан, кояш 6 да чыга, 18 сәгатьтә бата. Мондый очрак ел әйләнәсендә ике тапкыр кабатлана. Сөмбелә - башак дигән сүз.Ул – көзге бәйрәм, уңыш бәйрәме. Житен чәчле, зәңгәр күзле, зифа буйлы, сүзгә тапкыр, эшкә уңган кызны Сөмбелә дигәннәр. Нәүрүз бәйрәме язның башы булса, Сөмбелә көзне түгәрәкләү ае, чөнки бу вакытта урып-җыю эшләре төгәлләнә, ашлык сугылып келәт-амбарларга тутырыла. Татарларда Юлиан календарена кадәр зодиак календарь кулланылган һәм сигезенче ай «Сөмбелә» дип йөртелгән. Бу күренеш мәкальләрдә яхшы сакланган:
* Сөмбелә туса, су суыныр. * Сөмбеләдә урып ал, арышыңны чәчеп кал. Ә менә планетаның көньяк ярымшарында яшәүчеләр бу вакытта язны каршылый икән. Борынгы Русиядә элек-электән көн белән төн тигезләшкәндә төрле йолалар башкарганнар, бәйрәм иткәннәр. Келәтләр уңыш белән тулы, өстәлләр яшелчә-җимештән сыгылып торган мизгел дә бит әле бу. Шунлыктан кешеләр шатланып, күңел ачкан. Бай көзге табынны күпереп пешкән икмәк, кәбестә, мүк җиләгеннән пироглар бизәгән. Ә кызыл миләш тәлгәшләрен, чир-чордан, күз тиюдән сакласын дип, тәрәзә төбенә тезгәннәр.

27 октябрь көнне Совет районы мәктәпләре арасында "Көз сылуы Сөмбелә" ярышының район туры үткәрелде. Барлыгы 24 бала катнашты. Мәктәбебезнең данын яклап, 5 нче сыйныф укучысы Гөмәрова Риана катнашты. Эчтәлекле визиткасы, кул эшләре, көзге киемне тәкъдим итү, моңлы тавышы белән ул барлык кунакларны “таң калдырды”.

2 нче урынны яулап, призлы урынга чыкты. Афәрин!








# КҮКНЕҢ ҖИДЕНЧЕ КАТЫНДА








**Мәктәбебездә узган шимбәлек- ул матур тирәлектә ял итәргә теләгеңне тормышка ашыру, көзге матур көндә сыйныфташларың, мәктәп укучылары, укытучылары белән бергә җыйнаулашып мәктәп тирәлеген чистарту, аңа матурлык кертү, дияр идем мин. Бергәләп тырышканнан соң, эш нәтиҗәләреңне күрү ничек рәхәт?!**

**Октябрь аенда мәктәбебездә уздырылган шимбәлектә һәрберебез тырышып эшләде, берәүләр чүпләрне җыйса, икенчеләре аларны капчыкларга тутырды, өченчеләре исә капчыкларны илтеп куйдылар.**

**Бик күңелле һәм бердәм барды бу хезмәт. Эшнең нәтиҗәсе дә югары булды. Бар эшләрне дә төгәлләгәч, бергәләп кайнар чәй эчү, тәмле ризыклар авыз итү, күңелне тагын да күтәрде. Бергәләп эшләү, табигатьне ямьләндерүдә катнашу - һәрберебезнең изге бурычы.**

**Сафина Камилла, 10 нчы сыйныф укучысы**

**Редакциянең адресы:**420101, Казан шәһәре, Тулпар урамы, 2

Тел. 89050229576 **Тираж** – 50 экз.

**Баш мөхәррир һәм дизайнер:**
Габдуллаҗанова А.Ф.

**Редколлегия әгъзалары**:
Соколова София, Овезова Ләйлә, Сафина Камилла, Дзеба Карина